ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Физик культура һәм спорт турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 11 мартында
кабул ителде

**1 статья**

“Физик культура һәм спорт турында” 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 1 – 2, № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 3, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 1 пунктында “спорт клублары,” сүзләреннән соң “физкультура-спорт клублары һәм аларның берләшмәләре,” сүзләрен өстәргә;

2) 6 статьяның 1 өлешендә:
а) 3 пунктның “б” пунктчасында “спорт чараларының” сүзләреннән соң “, шул исәптән “Хезмәткә һәм спортка әзер” Бөтенроссия физкультура-спорт комплексын (алга таба – ГТО комплексы) гамәлгә ашыру буенча физкультура чараларын һәм спорт чараларын үз эченә алганнарның” сүзләрен өстәргә;
б) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ пункт өстәргә:
“$3^1$) коммерциягә карамаган оешмаларга ГТО комплексы сынаулары (тестлары) нормативларын үтәүне бәяләү хокукы бирү;”;

3) түбәндәге эчтәлекле $22^1$ статья өстәргә:
“$22^1$ статья. **ГТО комплексы. Төп эшчәнлекләре ГТО комплексын гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән физкультура-спорт клублары һәм аларның берләшмәләре**

ГТО комплексын гамәлгә ашыру, ГТО комплексын гамәлгә ашыра торган физкультура-спорт клублары һәм аларның берләшмәләре эшчәнлеген оештыру Федераль закон нигезендә башкарыла.”;

4) 28 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:

“$2^1$) ГТО комплексын гамәлгә ашыру өчен Федераль закон нигезендә шартлар тудыру;”;

5) 29 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“29 статья. **Физик культураны һәм спортны медицина ягыннан тәэмин итү**

1. Физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче затларны медицина ягыннан тәэмин итүгә түбәндәгеләр керә:

1) шушы затларның сәламәтлеге торышын системалы рәвештә тикшереп тору;

2) шушы затларга физик йөкләнешләрнең сәламәтлекләре торышына туры килүен бәяләү;

3) шушы затларның авыруларын профилактикалау һәм дәвалау, алар алган җәрәхәтләрне дәвалау, аларны медицина ягыннан реабилитацияләү;

4) аларның сәламәтлеген физик культура һәм спорт белән шөгыльләнгәндә кулланыла торган чаралар һәм ысуллар ярдәмендә торгызу.

2. Физик культура һәм спорт белән шөгыльләнергә теләүче затны спорт әзерлеген гамәлгә ашыра торган оешмага, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен башка оешмага кабул итү һәм (яисә) аңа ГТО комплексы сынаулары (тестлары) нормативларын үтәүгә рөхсәт бирү әлеге статьяның 4 өлеше нигезендә медицина тикшерүе үтүне раслый торган документлар булганда гына гамәлгә ашырыла.

3. Физкультура чараларын һәм спорт чараларын оештыручылар аларда катнашучыларны медицина ярдәме белән тәэмин итәргә тиеш.

4. Физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче затларга медицина ярдәме күрсәтүне оештыру тәртибе (шул исәптән физкультура чараларын һәм спорт чараларын әзерләгәндә һәм үткәргәндә) сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру, норматив-хокукый җайга салу функциясен башкара торган федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә, моңа оешмаларда спорт әзерлеге үтәргә, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнергә һәм (яисә) ГТО комплексы сынаулары (тестлары) нормативларын үтәргә теләгән затларга медицина тикшерүен үткәрү тәртибе дә керә.

5. Чит дәүләтләрдә медицина яисә фармацевтика белеме алган һәм чит дәүләтләрнең физкультура-спорт оешмалары тарафыннан медицина белгечләре сыйфатында тәкъдим ителгән затлар Татарстан Республикасында рәсми физкультура чаралары һәм спорт чаралары үткәрелү чорында бу чит дәүләтләрнең физкультура-спорт оешмалары вәкилләренә, рәсми физкультура чараларында һәм спорт чараларында катнашучыларга рәсми физкультура чараларын һәм спорт чараларын оештыручылар билгеләгән территорияләрдә медицина ярдәме күрсәтүне медицина яисә фармацевтика эшчәнлеген гамәлгә ашыруга Россия Федерациясе законнарында каралган рөхсәт алу процедурасын үтмичә генә башкару хокукына ия.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2016 елның 26 марты
№ 17-ТРЗ